ҖОМГА ХОТБӘСЕ

الحمد لله رب العالمين والصلاة والسلام على نبيه الكريم وعلى ءاله وأصحابه الطيبين الطاهرين، عباد الله أوصيكم ونفسي بتقوى الله العظيم والعمل بالشرع القويم

Аллаһ Тәгаләгә бөтен мактау-шөкерләр булсын!

Тиңдәше вә охшашы булмаган, бөтен кимчелекләрдән пак вә өстен булган Аллаһ Тәгаләгә мактауларыбыз булсын!

Аллаһ Тәгалә барча галәмне Үз көдрәте белән юктан бар итте, Аңа беркем дә ярдәм итмәде. Аллаһ Тәгалә әзәлдә әүвәлсез бар иде. Аңардан башка бер нәрсә дә юк иде – урын, тараф-җиһатлар, күкләр вә җирләр юк иделәр.

Аллаһ Тәгаләдә һич бер кимчелек юк. Аның чикләре вә гаятьләре юк.

Аллаһны уй-фикер белән төшенеп булмый, күз алдына китереп булмый.

Аллаһ Тәгалә бер нәрсәгә дә охшамый вә Аның охшашы юк. Ул һәр нәрсәне ишетә вә һәр нәрсәне күрә.

Безнең сәламыбыз иң сөекле булган Пәйгамбәребез Мухаммад – ‘Абдуллаһның улына!

Ул үз өммәтен хак юл белән алып баручы. Пәйгамбәребез – барча имамларның имамы. Шулай ук сәламыбыз – Пәйгамбәребезнең мөселман ыруларына, изге сахәбәләренә һәм бөтен Пәйгамбәрләргә булсын!

Аллаһның коллары! Үземә вә сезгә карата бөек нәсыйхәт: Аллаһның газәбынннын курыкыгыз – Аллаһка буйсынырга вә Шәригать буенча яшәргә һәм эшләргә кирәк. Кыямәт Көненә әзерләнү тиешле. Шул Көндә иманы дөрес булмаган кешегә бер нәрсә дә файда бирмәс – мал-акчалары да, балалары да ярдәм итмәсләр.

Хөрмәтле жәмәгать, белегез: Аллаһ Тәгалә безгә фәкать Тәүхидне тотарга – Аллаһ Тәгаләнең барлыгын вә берлеген таныргa Әмер бирде. Һәм Шәригать хөкемнәрен җиренә җиткереп үтәргә кушты. Һәм гөнаһларны эшләмәскә Әмер бирелде.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

(وَلِلهِ الْمَثَلُ الأَعْلَىَ)

«Уа лилляһиль-масалүль-а‘ля»

Мәгънәсе: Аллаһның күркәм Сыйфатлары бар. Аның Сыйфатлары беркемгә дә бернигә дә охшамас. Яралтучының Сыйфатлары мәхлүкатьләрнең сыйфатларына охшамас.

Шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтте:

(فَلاَ تَضْرِبُواْ لِلهِ الأَمْثَالَ)

«Фә лә´ тәдрибу´ лилля´һиль-әмсә´ль»

Мәгънәсе: Аллаһка охшаш юк – Аңарга охшаш я дә тиңдәш кушмагыз. Ул Берүзе тиңдәшсез вә охшашсыз.

Мухәммәд Пәйгамбәребездән Имам Әт-Тирмизий риваять иткән Хәдистә:

"إن لله تسعة وتسعين اسمًا مائة إلا واحدًا من أحصاها دخل الجنة"

«Иннә лилля´һи тис‘ату уа тис‘ы´на исман, миата илля´ уа´хидан, ман ахсо´һа´ дәхоляль-Джәннаһ»

Ягъни: Аллаһның Исемнәреннән 99 Исеме билгеле, кем Аларны санап әйтсә – Җәннәкә керер.

Мәгънәсе: кем Аллаһның Исемнәрен аңлап, дөрес ышанса – Җәннәткә керер.
Аллаһ Тәгаләнең Исемнәре кәмил, Аның кимчелеке булмаганын күрсәтә. Шул Исемнәрен Мухәммәд Пәйгамбәребез аңлатты. Аңа Җәбраил фәрештә вәхий китереп өйрәтте.
Аллаһны Аңа ләек булмаган исемнәр белән атарга ярамый.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

(ولله الأسماء الحسنى فادعوه بها وذروا الذين يلحدون في أسمائه)

«Уа лилляһиль-асма-уль-хусна фад‘уһу биһа уа заруллязина юльхидуна фи асма-иһ»

Мәгънәсе: Аллаһның Исенәре матур (кәмил) һәм шул Исемнәре белән Аллаһка ялварыгыз, сорагыз. Әмма кем Аллаһка ләек булмаган исем кушса – аларны тыңламагыз, ташлагыз вә аларның әйткәннәренә ышанмагыз.

Бу Аять безгә белдерә ки: Аллаһның Исемнәре бөтенесе кәмил, кимчелексез.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

«Аллаһ» дигән сүз – Яратучының Исемен аңлата. «Әррахмәни-Ррахим» – Аллаһ бу дөньяда мөселманнарга да, кәферләргә дә рәхмәтләр бирүче. Әмма Ахирәттә – фәкать мөселманнарга Аллаһ рәхмәтен бирә. Кәферләр Ахирәттә җәһәннәм утында мәңге калалар.

Әл-Мәлик – бөтен галәм Аллаһның мөлке, Аллаһныкы.

Әл-Куддүс – Аллаһ бөтен кимчелекләрдән пакъ, өстен. Ул бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел: Ул бер нинди урында да, тарафта да түгел.

Әс-Сәләм – Аңарда һичбер кимчелек юк.

Ъл-Мү´мин – Үз вәгъдәсен тоткан. Аль-Муһәймин – һәрбер колны Күрүче һәм Белүче (колларының сүзләрен, гамәлләрен вә ышануларын).

Шулай ук Аллаһның барча Исемнәре гүзәл – матур вә ямле.

Аллаһның Исемнәрен бозып-үзгәртеп әйтергә ярамый. Йыш була торган хәл – зикер әйтә торган кешеләрдә бу хаталар күп.

Кайсы бер кешеләр Аллаһның Исемен кирәкле хәрефләрен сузмыйча әйтәләр, я дә кайсы бер хәрефләрен әйтмиче калдыралар, мисал өчен «һ» хәрефен «х» – итеп, яки «г» итеп әйтәләр, – бу дөрес түгел.

Аллаһның газәбыннан курыккан кешеләр – тәква ияләре зикер укыганда Аллаһ Исемен дөрес әйткәннәр, үзгәртмиче, хатасыз.

Шулай ук Аллаһка кимчелек күрсәткән исемнәр кушарга ярамый.

Мисал өчен: «Аһ», «Иһ», «Уһ», чөнки барыбыз да беләбез: бу сүзләр авыртуны, арыганны аңлата. «Аһ», «Иһ», «Уһ» сүзләр кәмиллекне күрсәтмиләр. Бу сүзләр турында галимнәр әйттеләр: Аллаһ турында кулланырга ярамый.

Һәм билгеле: кешене Намаз укыганда «Аһ» дисә, аның Намазы бозыла, чөнки бу – авыртуны, сызлавны, арыганны белдерә.

Шул кешеләр хәдис булмаган, ялган сүзләргә таянып – Аллаһның Исемен «Аһ» – диеп әйтәләр – бу һич дөрес түгел! Шуңа охшаган хәдис юк. Андый сүзләрне кабатларга ярамый, кешеләргә дә өйрәтергә булмый.

Аллаһны Аңа ләек булмаган кушаматалар белән атарга ярамый. «Рух», я дә «акыл» исеме белән атарга ярамый. Чөнки рух белән акыл – яратылганнар, әүвәлләре бар, әмма Аллаһ – Яратучы, Ул – әүвәлсез.

Бөек Имам Әбу Җәгфәр Әт-Тахәвий Һиҗрәтнең 322 йылында вафат булды. Үзенең «Акыдә Әт-Тохәвийя» исемле китабында шулай әйтте:

“ومن وصف الله بمعنى من معاني البشر فقد كفر”

«Уа ман уасафаллаһа бима‘нам-мим-мә‘аниль-бәшәр – фәкодь кяфәръ»

Мәгънәсе: Кем Аллаһка Кеше сыйфатын кушса – көфер эшләгән була, Ислам Диненнән чыккан була.

Аллаһ Тәгаләнең Исеме нинди телдә язылган булса да – Аны хөрмәт итәргә тиешле.

Кем пычырак җирдә Аллаһ Исеме язылган кәгъаз тапса – шул кәгъазне күтәреп пычырактан чистартырга тиеш! Ә шул хәлдә пычырак эчендә калдырса – гөнаһлы булыр.

Әмма кем белеп торып чүплеккә, пычыракка Аллаһ Исеме язылган кәгъазне ыргырса, ташласа – Ислам Диненнән чыккан була, кәфер була.

Кем Дингә каршы сүзләр әйтсә – көферлек кылган булла. Мисал өчен әйткән булса: «Аллаһ – бу галәм», я дә: «бу галәм – Аллаһ», я дә: «Аллаһ белән галәм – бер» – дисә, кәфер була.

Имам Суфый Абу Бакр Ибн ‘Араби әйтте:

“من قال بالحلول فدينه معلول وما قال بالاتحاد إلا أهل الإلحاد”

«Мән каля биль-хүлүль фәдинуһу мә ‘лүл уә мә каля билль-иттихәд илля аһлүль-ильхәд»

«Кем әйткән булса: Аллаh бу галәмнең эченә керә – дисә – шундый кешенең иманы дөрес түгел (иманы юк, димәк), ә кем әйтсә: «Аллаһ белән галәм бер» – дисә – атеист була».

Кадерле Дин кардәшләребез! Мухәммәд Пәйгамбәребез безгә хак юлны күрсәтте. Кем Шәригатьне тота, Кыямәт Көненең газабыннан котылган булыр. Вә Җәннәткә газәбсез керер.

Аллаһ Тәгалә безгә фәкать Аллаһ Тәгаләнең барлыгын вә берлеген танырга Әмер бирде. Һәм Шәригать хөкемнәрен җиренә җиткереп үтәргә кушты. Вә гөнаһларны эшләүдән тыелырга Әмер бирде.

Кем Ахирәттә Җәннәт нигъмәтләрен теләсә – хәерле эшләрен күбәйтсен, аның яхшы нәтиҗәсен үзе күрер.

Аллаh Тәгаләдән үзем өчен дә, сезнең өчен дә гөнаһларыбызның ярлыкаун сорыйм.

هذا وأستغفر الله لي ولكم، فاستغفروا الله العظيم يرحمني ويرحمكم الله.